**ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ**

№ __78__

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«14» август 2014 ел.

«Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә
дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс
турында нигезләмәне раслау турында»

2004 елның 27 июленнән 79-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль закон, 2005 елның 1 февраленнән 112 номерлы “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында” Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә боерык бирәм:

1. Теркәлүче Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгының 2011 елның 22 мартыннан 42л/с номерлы “ТР ДТК Инспекциясендә ТР дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурсларны үткәрү турында нигезләмә раслау турында”гы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Юридик бүлеккә (Н.А. Курневич) әлеге боерыкны дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юлларга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгының беренче урынбасары И.Н. Плюснинга йөкләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең
«14» август 2014 ел,
78 номерлы боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә
дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына керүгә) карата конкурс турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба – конкурс комиссиясе) дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрүнең тәртибе һәм шартлары, һәм шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрүнең методикасы билгеләнә. Дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс (алга таба - конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә булган тигез мөмкинлегенә карата конституциячел хокукын, һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба - Инспекция) конкурс 2004 елның 27 июленнән “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 79-ФЗ номерлы Федераль закон) 22 статьясы һәм 2005 елның 1 февраленнән “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында” 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба - Указ), һәм шулай ук 2003 елның 16 гыйнварыннан “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында” 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә үткәрелә.

Конкурс граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Инспекциядәге конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы (алга таба - Башлык) тарафыннан Федераль закон

нигезендә конкурс буенча биләнә торган граждан хезмәтенең вакант (граждан хезмәткәре тарафыннан биләнмәгән) вазыйфасы булган очракта игълан ителә, аны биләү 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә башкарыла.

1.4. Конкурс үткәрү турында карар Башлык тарафыннан структур бүлекчә җитәкчесе әзерләгән дәлилле язма гариза нигезендә кабул ителә.

Конкурсны игълан итү белән берлектә, гаризада дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасының) исеме һәм, вазыйфаи йөкләмәләрнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата куелучы таләпләр булырга тиеш (әлеге Нигезләмәгә карата 1 номерлы кушымта).

1.6. Инспекциядә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) Инспекциядәге “җитәкчеләр” категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасы йөкләмәләрен билгеле бер вакытка биләүгә билгеләнгәндә;

б) ашыгыч хезмәт контракты төзелгәндә;

в) 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

г) граждан хезмәтендәге кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

д) граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә караучы граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.6. Инспекция боерыгы белән расланучы вазыйфалар исемлеге нигезендә, алар буенча вазыйфаи йөкләмәләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны куллануга бәйле булган граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләнгәндә, конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләренә һәм һөнәри әзерлекләренә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәтенә булган тигез мөмкинлекле булуга карата Россия Федерациясе гражданнарының хокукын, һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсә алу хокукын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының аерым норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелүче кандидатлар арасыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата аеруча туры килүче кандидатларны сайлап алу;

Инспекциянең кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителүче бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә барлык кандидатлар өчен дә тигез шартлар тудыру;

кандидатларны объектив профессиональ әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән конкурста катнашучылар арасыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфалары таләпләренә туры килүче затларны ачыклау.

2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Инспекциядә конкурс үткәрү өчен Башлык боерыгы белән конкурс комиссиясе оештырыла.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2.1. Инспекциядә билгеле булмаган вакытка “җитәкчеләр” категориясендәге граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы йөкләмәләрен биләүгә карата конкурсны үткәрү өчен конкурс комиссиясен Башлык җитәкли.

2.2.2. Граждан хезмәтенең башка вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурсларны үткәрү өчен Башлык боерыгы белән граждан хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе оешырга мөмкин.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, утырышны үткәрүнең көнен билгели һәм аның көн кадагын раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларны имзалый. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составы раслана.

Конкурс комиссиясе сәркатибе комиссия эшен (гаризаларны теркәүне, кабул итүне, эшләрне формалаштыруны, комиссия беркетмәләрен алып баруны) тәэмин итә.

2.4. Конкурс комиссиясе составына Инспекция Башлыгы, Башлыкның беренче урынбасары һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләтләнгән (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре бүлегеннән, юридик бүлектән, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс үткәрелүче структур бүлекчәнең) граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, һәм шулай ук Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең гаризасы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар - әлеге экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә, граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр буларак чакырылучы фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең кандидатуралары конкурс

комиссиясе составына кертелү өчен әлеге совет тарафыннан Башлык гаризасы буенча тәкъдим ителә.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен биләргә тиеш.

2.5. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурсларны үткәрү өчен конкурс комиссиясенең составы, аның буенча вазыйфаи вәкаләтләрне башкару дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны файдалануга бәйле булганга, Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителүче карарларга тәэсир итәрдәй мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык итеп оештырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына (кадрлар резервына керү өчен) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм әгәр дә анда барча әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик Инспекциядәге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурсны үткәрүнең шартларын регламентлаучы документларны, аны үткәрү өчен кирәкле булган методик һәм башка материалларны раслау турында;

конкурсны үткәрүнең план-графигын раслау турында;

конкурс нәтиҗәләрен чыгару турында;

конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны яулаган кандидатларны конкурсның җиңүчеләре итеп тану турында;

Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләү өчен Инспекциянең кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатларның исемлеген формалаштыру турында.

2.9. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларының гади күпчелеге тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч санала. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы кабул ителгән карар белән риза булмаганда үз фикерен белдерә ала, ул комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасының имзасы белән беркетелә.

2.10. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә һәм аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләүгә яисә мондый билгеләүдән баш тартуга нигез булып санала.

Конкурс комиссиясе граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Инспекциянең кадрлар резервына кертү турында киңәш рәвешендәге карар кабул итәргә хокуклы.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителүче карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясенең беркетмәсе (әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта) белән рәсмиләштерелә, ул рәис, рәиснең урынбасары, сәркатип һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.12. Конкурс процедурасын эшләү һәм әзерләү буенча документларның, конкурс комиссиясе утырышларындагы беркетмәләрнең эчтәлеге, конкурс биремнәренең сораулары һәм темалары конкурс тәмамланганчыга хәтле хезмәт файдалануындагы мәгълүмат булып санала.

2.13. Конкурс үткәрүне оештыру һәм тәэмин итү, конкурс комиссиясе эшләрен турыдан-туры Инспекциянең дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлеге гамәлгә ашыра.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Инспекциядәге граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатларга куелган таләпләргә җавап бирүче һәм билгеләнгән вакытка кирәкле булган барлык документларны тапшырган гражданнар (алга таба кандидатлар дип йөртелә) конкурста катнашуга кертелә.

Инспекциядәге граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатларга таләпләр (әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымта) һәм Инспекциядәге граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатлар тарафыннан тапшырылучы документларның һәм материалларның исемлеге (әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәтен регламентлаучы норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнгән.

3.2. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан Инспекциягә “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең рәсми сайтында (алга таба – Инспекциянең рәсми сайты) һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында конкурс үткәрү турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә тапшырыла.

3.3. Документларны нигезсез сәбәпләр булмыйча вакытында тапшырмау, аларны җитәрлек булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

## 4. Конкурсларны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларына каршы килмәүче ысуллар белән бәяләүгә нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Инспекциядәге граждан хезмәте вазыйфаларына карата кулланылучы квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының үрнәк исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәгә 5 номерлы кушымтада китерелә.

Конкурс үткәрелүче вазыйфаларның төркемнәренә һәм категорияләренә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

Нәтиҗәләр кандидатларның баллар буенча төзелгән исемлеге (рейтингы) рәвешендә бирелә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Инспекциянең һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында игълан, һәм шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның исеме, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата куелучы таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата кандидатлар тарафыннан тапшырылучы документлар һәм материаллар исемлеге (әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта) буенча тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итүнең тәмамлану вакыты, конкурсны үткәрүнең уйланылган вакыты, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар. Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта да басылырга мөмкин.

Конкурсның беренче этабы конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмати хәбәр Инспекциянең рәсми сайтында урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән дә иртәрәк булмаган чорда тәмамлана.

4.4.2. Кандидатлар тарафыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә), Инспекциянең кадрлар резервына керүгә карата тапшырылган документларны тикшергәннән соң, дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлек документларны кабул итү тәмамланганнан соң җиде көн эчендә гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә)

конкурста катнашуга рөхсәт бирү турында карар кабул итү яки аларны конкурста катнаштырудан дәлилле баш тарту өчен Башлыкка тәкъдим кертә.

Кандидатларның тикшерелгән документлары һәм дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлекнең тәкъдиме Башлыкка конкурсның икенче этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен тапшырыла.

4.4.3. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршы килүче шартлар ачыкланганда, аңа дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлек тарафыннан язма формада конкурста катнашуга кертелмәүнең сәбәпләре турында карар кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә хәбәр ителә (әлеге Нигезләмәгә карата 6 номерлы кушымта).

4.4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакант вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылуга хокуклы.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлану өчен билгеләнгән таләпләргә туры килүче кимендә ике кандидатның булуы шарт булып тора, бу алга таба кандидатларны сайлап алу мөмкинлеген бирә.

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлек, конкурсның икенче этабы башланырга 15 көн калганнан да соңармыйча, конкурста катнашуга рөхсәт бирелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) аның урыны һәм үткәрелү вакыты турында хәбәр юллый.

4.4.6. Конкурсның икенче этабы, конкурс игълан ителгән граждан хезмәте вазыйфаларының төркемнәренә һәм категорияләренә карап, өч төрле формада үткәрелергә мөмкин.

А. Граждан хезмәтенең өлкән вазыйфаларына конкурс үткәргәндә, икенче этап кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны анализлаудан һәм структур бүлекчә җитәкчеләре белән аерым әңгәмәләр үткәрүдән гыйбарәт *.

Б. Конкурсны граждан хезмәтенең алдынгы вазыйфаларына үткәргәндә икенче этапта түбәндәгеләр үткәрелә:

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларга анализ ясала;

кандидатларның һөнәри белемнәрен ачыклау максатында аналитик эшләр бәяләнә;

структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре белән аерым әңгәмәләр үткәрелә.

Аналитик эшне (рефератны) кандидатлар вакансияләренә карата конкурс үткәрелүче структур бүлекчәләр эшчәнлеге юнәлеше буенча әзерли. Аналитик эшләрне (рефератларны) бәяләү өчен Инспекциядәге кандидатларга тәкъдим ителгән аналитик эш (реферат) темасына бәйле өлкәдә эшләүче башка структур бүлекчәләрнең хезмәткәрләре җәлеп ителергә мөмкин.

Конкурсның икенче этабында әлеге вазыйфалар төркеме өчен кандидатларны бәяләгәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-

хокукый актларына каршы килми торган методлар белән бәяләүгә нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары (компьютер яки бланк аша тест үткәрү) кулланылырга мөмкин.

В. Граждан хезмәтенең төп вазыйфаларына карата конкурсның икенче этабы кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны анализлаудан, структур бүлекчәләрнең эшчәнлек юнәлешләре буенча аналитик эшләрне (рефератларны), һәм шулай ук Инспекция җитәкчелеге белән үткәрелгән аерым әңгәмәләрнең нәтиҗәләрен бәяләүдән гыйбарәт.

Әлеге вазыйфалар төркеме өчен кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларына, формалаштырылган методикаларны (тестларны) башкару нәтиҗәләрен анализлау нигезендә, төркемле дискуссияләр һәм махсус биремнәр барышында бәя бирелә. Биремнәрнең холкы һәм кандидатларга тәкъдим ителүче төркем дискуссияләренең булачак һөнәри эшчәнлеккә бәйле темалары экспертларның тәкъдимнәре нигезендә эшләнә һәм конкурс комиссиясе тарафыннан раслана.

4.4.7. Кандидатларны тест белән сынаулар язма формада үткәрелә. Конкурс комиссиясе дәгъва кылучыларга тест сынаулары өчен сораулар исемлеген төзи, һәм шулай ук дөрес булмаган җавапларның билгеле бер күләмен (яки процентын) раслый. Дөрес булмаган җавапларның мөмкин булган күләме 25 проценттан да күбрәк була алмый.

Сорауларның исемлеге гомуми танышу өчен мөмкин булырга тиеш. Тест сораулар исемлеге нигезендә төзелә һәм конкурста катнашучының түбәндәгеләрне белүен тикшерүне тәэмин итәргә тиеш:

Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен;

федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарын;

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе турындагы нигезләмәне;

граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның вазыйфаи регламентын;

структур бүлекчә эшчәнлеге юнәлеше буенча норматив-хокукый актларны.

Тесттагы сораулар 50дән артып китмәскә тиеш.

Дөрес җаваплар тигез күләмдә булган очракта катнашучыларга җаваплар өчен билгеле бер вакыт белән өстәмә тестлар бирелә.

4.4.8. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча башка вазыйфаи регламент нигезләмәләреннән, һәм шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары белән билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

4.4.9. Конкурс комиссиясе әгъзалары дәгъва кылучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлек тарафыннан һәр конкурска әзерләнә торган бәяләү битләрендә терки.

4.4.10. Конкурс башланыр алдыннан конкурс комиссиясенә рәислек итүче конкурс комиссиясе әгъзаларын турыдан-туры аны үткәрүнең тәртибе, бәяләрне кую, конкурс комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында инструктажлый.

4.4.11. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы конкурс комиссиясе сәркатибеннән бәяләү кәгазьләрен ала һәм тиешле балларны куя. Һәр бәяләү кәгазендә балларның гомуми саны куелганнан соң, конкурс комиссиясе әгъзасы бәяләү кәгазьләрен имзалый һәм аларны конкурс комиссиясе сәркатибенә тапшыра.

4.4.12. Бәяләү кәгазьләре нигезендә конкурс комиссиясе сәркатибе конкурста һәр катнашучы тарафыннан алынган барлык балларны куша.

Бәяләү кәгазендә төзәтмәләр рөхсәт ителми.

Кандидатларны бәяләүнең соңгы нәтиҗәләре анкетага теркәлә (әлеге Нигезләмәгә 7 номерлы кушымта).

4.5. Икенче этапның нәтиҗәсе һәм шул ук вакытта конкурсның соңгы нәтиҗәләре булып конкурс комиссияләре тарафыннан әзерләнгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә кандидатларның рейтинглары санала.

Конкурс нәтиҗәләрен чыгару һәм граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата кандидат турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

кандидатлар тарафыннан барлык конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрендә алынган бәяләү критерийлары буенча балларның суммалары;

кандидат дәгъва итүче вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчеләренең (Инспекция җитәкчелеге фикере) кандидатлар белән әңгәмә (әңгәмәләр) үткәрү нәтиҗәсендәге фикере.

Конкурс комиссиясе конкурсның җиңүчесе турындагы карарны, һәм шулай ук Инспекциянең кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатларның исемлекләрен раслый.

4.6. Әгәр дә конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең конкурс игълан ителгән вакант вазыйфасы буенча кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурсны үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.7. Башлык яңа конкурс үткәрү турында яисә вакант вазыйфаны биләү өчен куелган таләпләргә аеруча туры килүчене һәм конкурста катнашып иң күп балл җыючыны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) турында карар кабул итә.

4.8. Әгәр дә конкурста ике яки аннан да күбрәк катнашучы тигез күләмдә балл җыйса, конкурс комиссиясе рәисенең фикере хәлиткеч санала.

4.9. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча биш көн эчендә конкурс комиссиясе карары кабул ителә, ул беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясенә рәислек итүче, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурсның җиңүчесен дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү турында Инспекция боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – конкурсның җиңүчесен кадрлар резервына кертү, тиешле язуны һәм граждан хезмәткәренең хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документларын граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп, Инспекциянең боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Шул ук вакытта вазыйфалар исемлеге нигезендә, конкурста җиңүчене вазыйфага билгеләүгә тәкъдим иткәндә, Башлыкка мәҗбүри тәртиптә конкурс комиссиясенең карары һәм комиссия тарафыннан мондый карарны кабул итүгә нигез булган материаллар тапшырыла.

4.11. Әгәр дә конкурста җиңмәгән кандидатны конкурс комиссиясе тарафыннан граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен Инспекциянең кадрлар резервына кертү карары кабул ителсә, ул вакытта, күрсәтелгән затның ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс игълан ителгән граждан хезмәте вазыйфасы караган шул ук төркемнең граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, аны Инспекциянең кадрлар резервына кертү турында Инспекция боерыгы чыгарыла.

4.12. Конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә анда катнашкан кандидатларга дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча бүлек тарафыннан конкурс нәтиҗәләре турында язма формада хәбәр ителә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шулай ук билгеләнгән вакытта Инспекциянең һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.13. Конкурска кертелмәгән граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга язма гариза буенча конкурс тәмамланганнан соң өч ел дәвамында кире кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге вакыт узганчы документлар Инспекция архивында саклана, аннан соң юк ителә.

4.14. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурсны үткәрү урынына килү һәм кире китү, торак бинаны вакытлыча файдалануга алу, элемтә хезмәтләреннән файдалану һ.б.) кандидатларның үз хисапларыннан каплана.

* Әлеге этапта кандидатларны бәяләү өчен өстәмә рәвештә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү өчен тест (бланкта, компьютерда) үткәрелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә
дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата
конкурс турында нигезләмәгә
**1 кушымта**

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе
башлыгына

________________________
(инициаллар, фамилия)

ГАРИЗА

«___»________ 201__ ел.

Сездән дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) карата конкурс игълан итүегезне сорыйм

________________________________________________________________
(вазыйфаның исеме)

________________________________________________________________
(структур бүлекчәнең исеме)

Әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата түбәндәге таләпләр куела:

